ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 ноябрь, 2021 ел № 9/10

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясенең Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
9/10 Карарына
кушымта
3 ноябрь, 2021 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
муниципаль торак контроле турында
Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен (алга таба – муниципаль контроль) билгели.

2.Муниципаль контроль предметы булып юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең һәм гражданнарның (алга таба – контрольдәге затларның) торак законнары, энергияне саклап тоту һәм муниципаль торак фондында энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү турында законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәве тора, атап әйткәндә:

1) түбәндәге таләпләр:

- торак фондыннан файдалану һәм аны саклауга карата;

- торак, аннан файдалану һәм аны карап тотуга карата;

- күпфатирлы йортларда торак милекчеләренең гомуми милкеннән файдалану һәм аны карап тотуга карата;

- күпфатирлы йортта яшәү өчен торакны яшәү өчен булмаган торакка, яшәү өчен булмаган торакны яшәү өчен торакка күчерү тәртибенә карата;

- күпфатирлы йортта торакны яңадан планлаштыру һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибенә карата;

- капиталь ремонт фондларын формалаштыруга карата;

- күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы, күпфатирлы йортларда гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлауны башкаручы һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүче юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә карата;

- күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм торактан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә карата;

- ресурс белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген башкаручы затлар тарафыннан торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – система) мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата;

- күпфатирлы йортларда инвалидлар өчен уңайлы мохит булдыруга карата;

- социаль файдаланудагы наемга алынган йортларда торак урыннар бирүгә карата;

2) торак йортларның һәм күпфатирлы йортлардагы торакларның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэминителешенә һәм энергетика нәтиҗәлелегенә карата таләпләр;

3) күпфатирлы йортта гомуми милек белән идарә итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләрне тиешле дәрәҗәдә башкармау, билгеләнгән вакыттан озаграк һәм (яки) тәнәфесләр белән башкару очрагында,

торакны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен;

4) күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту;

5) торакны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү;

6) күпфатирлы торак йортлардагы торак милекчеләренә һәм торактан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату, туктатып тору һәм чикләү.

Муниципаль контроль предметы булып контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның үтәлеше дә тора.

3. Муниципаль контроль объектлары (алга таба – контроль объекты) булып тора:

- эшчәнлекне гамәлгә ашыручы контрольдәге затларның эшчәнлегенә, гамәлләренә (гамәл кылмавына) мәҗбүри таләпләр, шул исәптән таләпләрне үтәргә тиешле контрольдәге затларның эшчәнлегенә, гамәлләренә (гамәл кылмавы) карата;

- контрольдәге затларның эшчәнлеге, шул исәптән мәҗбүри таләпләр куела торган эшләр һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре;

- аларга карата мәҗбүри таләпләр куелган, контрольдәге затлар ия булган һәм (яки) алар файдалануындагы биналар, корылмалар, төзелмәләр, территорияләр, җир участоклары, предметлар һәм башка объектлар.

4. Контроль объектларын исәпкә алу өчен түбәндәгеләрне булдыру кирәк:

- контроль чараларының бердәм реестрын;

- ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән башка дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларын.

Контроль орган тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 16 статьясындагы 2 өлеше һәм 17 статьясындагы 5 өлеше нигезендә мәгълүмат системасын кулланып контроль объектларын исәпкә алу алып барыла.

5. Муниципаль контроль Башкарма комитетның вәкаләтле органы (алга таба – Контроль орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру белән җитәкчелекне вәкаләтле орган җитәкчелеге башкара.

7. Контроль орган исеменнән муниципаль контрольне түбәндәге вазыйфаи затлар башкарырга хокуклы:

1) Контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары);

2) әлеге Нигезләмә, вазыйфаи регламент яисә вазыйфаи инструкция нигезендә муниципаль контроль төре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү кергән Контроль органның вазыйфаи заты (алга таба – инспектор).

Контроль органның тикшерү чарасын үткәрү турында карар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары булып Контроль орган җитәкчесе, җитәкче урынбасары (алга таба – Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затлары) тора.

8. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә хокукларга, бурычларга һәм җаваплылыкка ия.

9. Контроль орган судка түбәндәге гаризалар белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы:

1) Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен бозып, күпфатирлы йортта торак милекчеләренең яки торак милекчеләре ширкәтенең, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышында кабул ителгән карарны гамәлдә түгел дип тану турында;

2) торак милекчеләре ширкәтен, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативын бетерү турында – мондый ширкәт яки кооператив уставының, уставка кертелгән үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләренә тәңгәл килмәве ачыкланганда, бетереп булмый торган хокук бозулар булган очракта, мондый ширкәт яки кооперативны төзү тәртибендәге хокук бозулар ачыкланганда;

3) күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсен, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсен яисә күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм (яки) ремонтлау буенча эшләрне башкару буенча хезмәт күрсәтү шартнамәсен гамәлдә түгел дип тану турында – билгеләнгән срокта идарәче оешманы сайлап алу, күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенең шартларын раслау турында һәм аны төзү турында, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсен төзү турында, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм (яки) ремонтлау буенча эшләрне башкару турында Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен бозуларны бетерү турында, күрсәтелгән шартнамәләрнең шартларын раслау турында күрсәтмәләр үтәлмәгән очракта;

4) мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең, торак яллаучыларның һәм башка файдаланучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, аларның мөрәҗәгатьләре буенча яки билгесез затлар даирәсенең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга;

5) социаль файдаланудагы торак фондындагы торакның наем шартнамәсен гамәлдә түгел дип тану турында, әлеге шартнамәнең Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килмәвен бетерү турында күрсәтмә билгеләнгән срокта үтәлмәгән очракта;

6) күрсәтмәне үтәргә мәҗбүр итү турында.

10. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

11. Контроль органның вазыйфаи затлары һәм башка вәкаләтле затлар тарафыннан башкарыла торган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында контрольдәге затларга мәгълүмат бирү контрольлек (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында, шулай ук Интернет челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында күрсәтелгән гамәлләр һәм карарлар турында белешмәләр урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 2. Зыян (зарар) китерү куркынычы категорияләре

12. Муниципаль торак контроле профилактик чараларны һәм контроль чараларны сайлап алуны, аларның эчтәлеген (шул исәптән тикшерелә торган

мәҗбүри таләпләрнең күләме), интенсивлыгын һәм нәтиҗәләрен билгели торган зыян (зарар) китерү куркынычы белән идарә итү нигезендә гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта Контроль орган тарафыннан даими рәвештә зыян (зарар) китерү куркынычын бәяләү һәм идарә итү өчен кулланыла торган белешмәләргә мониторинг (җыю, эшкәртү, анализ һәм исәпкә алу) үткәрелә.

13. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, зыян (зарар) китерү куркынычы белән идарә итү максатларында, контроль объектлары түбәндәге зыян (зарар) китерү куркынычы категорияләренең (алга таба – куркыныч категориясенә) берсенә кертелергә мөмкин:

- югары дәрәҗә куркыныч;
- уртача дәрәҗә куркыныч;
- уртачадан кимрәк дәрәҗә куркыныч;
- түбән дәрәҗә куркыныч.

14. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү критерийлары әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы белән билгеләнгән.

15. Контроль объектын куркынычның бер категориясенә кертү ел саен аның характеристикаларын расланган куркыныч критерийлары белән чагыштыру нигезендә Контроль орган тарафыннан гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторы булып контроль объектының параметрларына туры килү яисә килмәве тора, алар үзләре мәҗбүри таләпләрне бозу дип саналмый, ләкин закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы булуын югары дәрәҗәдә раслый.

16. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында билгеләнгән.

17. Контроль объекты билгеле бер куркыныч категориясенә кертелмәгән очракта, ул түбән дәрәҗә куркыныч категориясенә кертелгән дип санала.

18. Контроль орган контроль объектының куркынычның башка категориясе критерийларына туры килүе яки куркыныч критерийларын үзгәртү турында мәгълүмат кергән көннән алып биш эш көне эчендә контроль объектының куркыныч категориясен үзгәртү турында Карар кабул итә.

## 3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда үткәрелә торган профилактик чаралар төрләре

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Контроль орган түбәндәге профилактик чаралар үткәрә:

1) мәгълүмат бирү;
2) хокук куллану практикасын гомумиләштерү;
3) кисәтү ясау;
4) консультация бирү;
5) профилактик визит.

Контроль орган контрольдәге затларга һәм башка кызыксынган затларга мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча хәбәр итүне Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән мәгълүматларны Яр Чаллы шәһәренең «Интернет» челтәрендәге (алга таба – рәсми сайт) рәсми сайтында, массакүләм

мәгълүмат чараларында, контрольдәге затларның дәүләт мәгълүмат системаларында шәхси кабинетлары аша (алар булганда) һәм башка формаларда гамәлгә ашыра.

Муниципаль контрольне оештыру һәм үткәрү буенча хокуктан файдалану практикасын гомумиләштерү ел саен башкарыла.

Контроль орган хокуктан файдалану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча Контроль органының хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре белән доклад әзерләүне тәэмин итә (алга таба – доклад).

Доклад Контроль орган җитәкчесе тарафыннан раслана һәм рәсми сайтта ел саен, хокуктан файдалану практикасын гомумиләштерү елыннан соң килүче елның 30 гыйнварыннан да соңга калмыйча урнаштырыла.

## 4. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү

19. Мәҗбүри таләпләрне бозу яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында мәгълүматлар булганда, һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозуның закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүе яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы хакында расланган мәгълүматлар булмаган очракта Контроль орган контрольдәге затка мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү ясый (алга таба – кисәтү) һәм мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итә.

Кисәтү Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типик рәвешләре турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча языла.

20. Контроль орган мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләрне исәпкә ала һәм тиешле мәгълүматларны контроль чаралар һәм башка профилактик чаралар үткәргәндә куллана.

## 5. Консультация бирү

21 Контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә консультация бирү түбәндәге муниципаль контрольне оештыру һәм тормышка ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча гамәлгә ашырыла:

1) контроль чаралар үткәрү тәртибе;

2) контроль чаралар үткәрү вакыты;

3) контроль чаралар нәтиҗәләре буенча карарлар кабул итү тәртибе;

4) Контроль орган карарларына шикаять бирү тәртибе.

22 Инспекторлар контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә консультацияләрне:

1) телефон буенча телдән аңлатмалар рәвешендә, видео-конференц-элемтә аша, шәхси кабул итүдә яисә профилактик чара, контроль чара уздыру барышында бирә;

2) рәсми сайтта контрольдә тотылучы затларның контроль органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган бер типтагы мөрәҗәгатьләре (10 нан артык бер типтагы мөрәҗәгать) буенча язма аңлатма урнаштыру юлы белән бирә.

23. Мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү барышында инспекторлар тарафыннан шәхси консультация бирү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

Телефон аша сөйләшү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

24. Контроль орган контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә телдән бирелгән консультация буенча язмача мәгълүмат бирми.

25. Контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә түбәндәге сораулар буенча язмача консультация бирелә:

1) Контроль орган карарларына шикаять бирү тәртибе;

2) контроль чаралар үткәрү;

3) җаваплылык чараларын куллану.

26. Контрольдәге зат «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән срокларда язмача җавап бирү турында гариза җибәрергә хокуклы

27. Контроль орган үткәрелгән консультацияләр исәбен алып бара.

## 6. Профилактик визит

28. Профилактик визит инспектор тарафыннан контрольдәге затның эш урынында профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән үткәрелә.

Профилактик визитның дәвамлылыгы эш көненең ике сәгатеннән дә артмый.

29. Инспектор мәҗбүри профилактик визит үткәрә:

1)күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашырчы контрольдәге затларга карата, мондый эшчәнлек башланганнан соң бер елдан да соңга калмыйча (эшчәнлекне башлау турында мәгълүматлар булганда);

2) югары дәрәҗә куркыныч категориясендәге контроль объектларына карата, контроль объектын күрсәтелгән категориягә кертү турында карар кабул ителгән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча.

30. Профилактик визитлар контрольдәге затлар белән килешенеп үткәрелә.

31. Контроль орган контрольдәге затка профилактик визит үткәрү турында аны үткәрү датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр җибәрә.

Контрольдәге зат профилактик визит уздырудан (мәҗбүри профилактик визитны да кертеп) баш тартырга хокуклы, бу хакта Контроль органга аны үткәрү датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

32. Профилактик визит нәтиҗәләре буенча инспектор профилактик визит үткәрү турында акт төзи, аның формасы Контроль орган тарафыннан раслана.

33. Контроль орган үткәрелгән профилактик визитларның исәбен алып бара.

## 7. Муниципаль контроль кысаларында үткәрелә торган контроль чаралар

34. Муниципаль контроль Контроль орган тарафыннан түбәндәге планлы һәм планнан тыш тикшерү чараларын үткәрүне оештыру юлы белән гамәлгә ашырыла:

- инспекция визиты, документар тикшерү, күчмә тикшерү;
- мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, күчмә тикшерену.

35. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контрольдәге затлар белән аралашу түбәндәгечә башкарыла:

- инспектор һәм контрольдәге зат яки аның вәкиле белән очрашулар, телефон аша һәм башкача сөйләшүләр (турыдан-туры бәйләнеш);

- документларны, башка материалларны соратып алу;

- инспекторның контрольдәге затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында булуы (инспекторның керү өчен ирекле җитештерү объектларында булу очракларыннан тыш).

36. Контрольдәге зат белән үзара аралашканда Контроль орган тарафыннан башкарыла торган контроль чаралар үткәрү нигезләре:

1) Контроль органда зыян (зарар) китерү яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы турында белешмәләрнең булуы яки объектның мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәвен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чараларны үткәрү вакыты җитү;

3) Россия Федерациясе Президенты күрсәтмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контрольдәге затларга карата контроль чаралар үткәрү турында күрсәтмәсе;

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында контроль орган карарын үтәү вакытының тәмамлануы – Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлеше белән билгеләнгән очракларда.

37.Үзара бәйләнешсез контроль чаралар Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затларының биремнәре, шул исәптән Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, контроль органның эш планындагы биремнәрне дә кертеп, инспекторлар тарафыннан үткәрелә.

38. Контрольдәге затлар белән үзара бәйләнешсез үткәрелә торган чаралардан тыш, планлы һәм планнан тыш контроль чаралар, инспектор һәм контроль чараларын үткәрүгә җәлеп ителгән затлар тарафыннан түбәндәге контроль гамәлләр башкару юлы белән үткәрелә: карау, сораштыру, язмача аңлатмалар алу, документларны соратып алу, экспертиза.

39. Контрольдәге затлар белән үзара бәйләнешне, шулай ук документлар тикшерүне күздә тоткан контроль чарасын үткәрү өчен Контроль органның вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган контроль органы карары кабул ителә, анда Федераль законның 64 статьясындагы 1 өлешендә каралган мәгълүматлар күрсәтелә.

Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүне, күчмә тикшеренүне үткәрүгә карата Нигезләмәнең әлеге пунктының беренче абзацында каралган тәртиптә карар кабул итү таләп ителми.

40. Контроль чаралар Контроль органның контроль чаралар үткәрү турындагы карарында күрсәтелгән инспекторлар тарафыннан үткәрелә.

Кирәк булганда, Контроль орган тикшерү чараларын үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән һәм контроль чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар, эксперт оешмалары реестрына кертелгән экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

41. Контрольдәге затлар белән үзара бәйләнешле Контроль чарасы тәмамланганнан соң, инспектор Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типик рәвешләре турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча контроль чарасы актын (алга таба – акт) төзи .

Мондый чара үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланса, актта нинди мәҗбүри таләп бозылуы, аның нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге тарафыннан билгеләнүе күрсәтелә.

Контрольдәге зат белән үзара бәйләнешне күздә тоткан контроль чарасы тәмамланганчы ачыкланган бозуларны бетергән очракта актта аны бетерү факты күрсәтелә.

42. Актка мәҗбүри таләпләрне бозу дәлиле булган документлар, башка материаллар теркәлә.

Актка тикшерү чарасын уздырганда тутырылган тикшерү кәгазьләре теркәлергә тиеш.

43. Актны рәсмиләштерү, әгәр Россия Федерациясе законнары белән актны рәсмиләштерүнең башка тәртибе билгеләнмәгән булса, мондый чараны үткәрү тәмамланган көнне контроль чара үткәрү урынында башкарыла.

44. Дәүләт, коммерция, хезмәт, башка серләрне тәшкил иткән контроль чарасы нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

## 8. Контроль чаралар нәтиҗәләре буенча Контроль орган тарафыннан күрелә торган чаралар

45. Контроль чара үткәргәндә контрольдәге зат тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта Контроль орган бурычлы:

1) контроль чара актын рәсмиләштергәннән соң контрольдәге затка ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү һәм (яисә) законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне булдырмау чараларын үткәрү турында, шулай ук контроль рәвешендә федераль законда каралган башка чаралар үткәрү турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә) бирелә, анда бетерүнең алты айдан да артык булмаган тиешле сроклары күрсәтелә (документар тикшерү уздырганда күрсәтмә контрольдәге затка документар тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә);

2) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне булдырмау яки аны туктату буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны биналар, корылмалар, төзелмәләр, тораклар, җиһазларны, транспорт чараларын һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләүне (куллануны) тыю турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать итүгә һәм, контроль объектына ия булган һәм (яки) аннан файдаланучы гражданнар, оешмалар, алар тарафыннан биналар, корылмалар, төзелмәләр, тораклар, җиһазлар, транспорт чаралары һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләү (файдалану) эшчәнлеге, алар тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарлар, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын тудырса, мондый гражданнарга, оешмаларга закон

тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычы һәм аны булдырмау ысуллары турында теләсә нинди үтемле мәгълүмат белән җиткерүгә кадәр;

3) контроль чарасы барышында җинаять яки административ хокук бозу билгеләрен ачыклаганда, тиешле мәгълүматны үз компетенциясе нигезендә яисә тиешле вәкаләтләр булганда, гаепле затларны законда билгеләнгән җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә, тиешле мәгълүматны дәүләт органына җибәрергә;

4) мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне булдырмау буенча, күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән очракта, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать иткәнгә кадәр, аның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә, әгәр мондый чара законнарда каралган булса;

5) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән мәҗбүри таләпләрне үтәү, башка чаралар үткәрү буенча рекомендация бирү турындагы мәсьәләне карарга.

46. Күрсәтмәнең үтәлү срогы чыкканчы, контрольдәге зат күрсәтмәнең үтәлеше турында, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне раслаучы документлар һәм белешмәләр кушып, Контроль органга хәбәрнамә җибәрә.

47. Контрольдәге зат күрсәтмәне үтәгән очракта, Контроль орган аңа күрсәтмәнең үтәлеше турында хәбәрнамә җибәрә.

48. Әгәр күрсәтелгән документлар һәм мәгълүматлар контрольдәге зат тарафыннан тапшырылмаган булса, яки алар нигезендә яисә мәҗбүри таләпләрне (куркынычсызлык мониторингы) үтәүне күзәтү кысаларында алынган мәгълүмат нигезендә карарның үтәлеше турында нәтиҗә ясарга мөмкин булмаса, Контроль орган әлеге карарның үтәлешен инспекция визиты яисә документлар тикшерү белән бәяли.

Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарның үтәлешенә бәя бирелгән очракта, күчмә тикшерү үткәрергә рөхсәт ителә.

49. Әгәр Контроль орган тарафыннан контроль чараны үткәрү нәтиҗәләре буенча карарның үтәлмәве яки тиешенчә үтәлмәве ачыкланса, ул контрольдәге затка, әлеге Нигезләмәнең 45 пунктындагы 1 пунктчасында каралган карарны, аны үтәүнең яңа срокларын күрсәтеп, яңадан тапшыра.

Күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән очракта Контроль орган, аның үтәлешен тәэмин итү буенча күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать итүгә кадәр (әгәр мондый чара законнарда каралган булса) чаралар күрә.

## 9. Планлы контроль чаралары

50. Планлы контроль чаралары чираттагы календарь елына Контроль орган тарафыннан төзелә торган һәм прокуратура органнары белән килештерелергә тиешле планлы тикшерү чаралары планы (алга таба – еллык чаралар планы) нигезендә үткәрелә.

51. Куркынычның аерым категорияләренә кертелгән контроль объектларына карата планлы тикшерү чаралары үткәрү төрләре, вакыты зыян (зарар) китерү куркынычыннан чыгып билгеләнә.

52. Контроль орган планлы контроль чараларының түбәндәге төрләрен үткәрә ала:

1) инспекция визиты;

2) документар тикшерү;

3) күчмә тикшерү.

Югары дәрәҗә куркыныч категориясенә керә торган объектларга карата елына кимендә бер тапкырдан кимрәк булмаган, әмма ике тапкырдан артмаган контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелә.

Уртача яки уртачадан кимрәк дәрәҗә куркыныч категориясенә керә торган объектларга карата түбәндәге чаралар үткәрелә: алты елга кимендә бер контроль (күзәтчелек) чарасы һәм өч елга бер тапкырдан артык булмаган контроль (күзәтчелек) чарасы.

53. Контроль объектларына карата планлы тикшерү чаралары үткәрү периодлары:

- югары дәрәҗә куркыныч категориясе өчен - 2 елга бер тапкыр;
- уртача дәрәҗә куркыныч категориясе өчен - 3 елга бер тапкыр;
- уртачадан кимрәк дәрәҗә куркыныч категориясе өчен -5 елга бер тапкыр.

Түбән дәрәҗә куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектына карата планлы контроль чаралары үткәрелми.

54. Гражданнар файдалануындагы торак урыннарына карата муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда, планлы контроль чаралары үткәрелми.

## 10. Планнан тыш контроль чаралары

55. Планнан тыш контроль чаралар документар һәм күчмә тикшерүләр, инспекция визиты, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, күчмә тикшеренү рәвешендә үткәрелә.

56. Планнан тыш контроль чарасын үткәрү турында карар мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторларын исәпкә алып кабул ителә.

57. Планнан тыш контроль чаралар, үзара бәйләнешсез планнан тыш тикшерү чараларыннан тыш, Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 1, 3-5 пунктларында каралган нигезләр буенча үткәрелә.

58. Планнан тыш контроль чарасын үткәрү прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң гына рөхсәт ителсә, әлеге чара мондый килешүдән соң үткәрелә.

## 11. Документар тикшерү

59. Документар тикшерү – Контроль органның урнашу урынында үткәрелә торган контроль чара, аның предметы – контрольдәге затларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган документларындагы белешмәләр, шулай ук аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда кулланыла торган, контроль (күзәтчелек) органының мәҗбүри таләпләрен һәм карарларын үтәү белән бәйле документлар.

60. Контроль орган каравындагы документларда булган белешмәләрнең дөреслеге шик тудырса яки бу белешмәләр контрольдәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирми икән, Контроль орган

контрольдәге зат адресына документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбен җибәрә.

Әлеге таләп алынганнан соң ун эш көне эчендә контрольдәге зат таләпләрдә күрсәтелгән документларны контроль органга җибәрергә тиеш.

61. Документар тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмаска тиеш.

Күрсәтелгән срокка кертелми:

1) Контроль орган тарафыннан контрольдәге затка документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны соратып алу таләбен җибәргәннән алып таләптә күрсәтелгән документларны Контроль органга тапшырганчы үткән вакыт;

2) контрольдәге затка Контроль органның мәгълүмат җибәрү вакыты.

62.Документар тикшерү барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

1) документлар таләп итү;

2) язма аңлатма алу;

3) экспертиза.

63.Контроль чара үткәрү барышында инспектор контрольдәге затка контрольдәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү өчен кирәкле һәм (яки) әһәмиятле булган документларны һәм (яки) аларның күчермәләрен, шул исәптән фотосурәтләр, аудио һәм видеоязмалар, мәгълүмат базалары, мәгълүмат банкларын, шулай ук электрон мәгълүматны йөртү чараларын таләп итәргә хокуклы.

Контрольдәге зат Контроль органга документларны тапшыру турындагы таләптә күрсәтелгән срокта кирәкле документларны җибәрә яисә инспекторга, тиешле вакытка документлар җибәрмәү сәбәпләрен һәм кирәкле документларны җибәрү мөмкин булган вакытны күрсәтеп, документларны билгеләнгән срокта тапшыру мөмкинлеге булмавы турында үтенеч хаты җибәрә.

Фотосурәтләргә, аудио - һәм видеоязма материалларына, мәгълүмат базаларына, мәгълүмат банкларына, шулай ук электрон мәгълүмат йөртү чараларына логин һәм пароль рәвешендә, документар тикшерү вакытына контроль чаралар үткәрү өчен кирәк булган мәгълүматны карау һәм эзләү хокукы бирелә.

64. Инспектор тарафыннан контрольдәге заттан яки аның вәкиленнән, шаһитлардан язмача аңлатмалар соратып алынырга мөмкин.

Күрсәтелгән затлар инспекторга тикшерү тәмамланганчы ике эш көненнән дә соңга калмыйча ирекле формада язмача аңлатма бирә.

Язмача аңлатмалар ирекле формада язма документ төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

Инспектор контрольдәге затлар, аларның вәкилләре, шаһитлар, вазыйфаи затлар яки оешма хезмәткәрләре сүзләреннән язмача аңлатмалар төзергә хокуклы. Бу очракта күрсәтелгән затлар аңлатмалар белән танышалар, кирәк булганда, текстны тулыландыралар, инспекторның аларның сүзләреннән дөрес язулары турында билге ясыйлар, документны төзү датасын һәм урынын күрсәтеп, кул куялар.

65. Экспертиза Контроль орган кушуы буенча эксперт яки эксперт оешмасы тарафыннан башкарыла.

Экспертиза контрольдәге затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләр) урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында, шулай ук эксперт яки эксперт оешмасы эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында үткәрелергә мөмкин.

Экспертиза үткәрү вакыты экспертиза төренә бәйле һәм Контроль орган белән эксперт яки эксперт оешмасы арасындагы килешү буенча һәр конкрет очракта аерым билгеләнә.

Экспертиза нәтиҗәләре эксперт бәяләмәсе белән Контроль орган тарафыннан расланган форма буенча рәсмиләштерелә.

66. Актны рәсмиләштерү Контроль орган урнашкан урында документар тикшерү үткәрү тәмамланган көнне башкарыла.

67. Акт Контроль орган тарафыннан контрольдәге затка, Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә, документар тикшерү тәмамланганнан соң ун эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

## 12. Күчмә тикшерү

68. Күчмә тикшерү контрольдәге затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләрнең) урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында үткәрелә.

Күчмә тикшерү дистанцион аралашу чараларын кулланып, шул исәптән аудио яки видеоэлемтә ярдәмендә үткәрелергә мөмкин.

69. Күчмә тикшерү түбәндәге очракта үткәрелә:

1) Контроль орган карамагында булган яки ул соратып ала торган документларда һәм контрольдәге затның аңлатмаларында булган белешмәләрнең тулылыгы һәм дөреслеге белән танышу мөмкин булмаганда;

2) контрольдәге затның һәм (яки) аның милкендәге һәм (яки) карамагындагы контроль объектларының әлеге Нигезләмәнең 12.1 пунктында күрсәтелгән урынга чыкмыйча гына эшчәнлеген, гамәлләрен (гамәл кылмавын) һәм контроль чараларының башка төре кысаларында каралган кирәкле контроль гамәлләр кылуның мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү мөмкин булмаганда.

70. Планнан тыш тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп, аны үткәрү очракларыннан тыш, Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә үткәрелергә мөмкин.

71. Контроль орган контрольдәге затка күчмә тикшерү үткәрү турында, күчмә тикшерү башланганчы егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча, аны үткәрү турындагы карарның күчермәләрен җибәреп, хәбәр итә.

72. Инспектор күчмә тикшерү уздырганда контрольдәге затка (аның вәкиленә) хезмәт таныклыгын, күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарның күчермәсен күрсәтә, шулай ук контроль чараларның бердәм реестрындагы хисап номерын хәбәр итә.

73. Күчмә тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмый.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата күчмә тикшерү барышында үзара аралашуның гомуми вакыты кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

74. Күчмә тикшерү барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

1) карау;

2) сораштыру;

3) документлар таләп итү;

4) язмача аңлатма алу;

5) экспертиза.

75. Карау инспектор тарафыннан контрольдәге зат һәм (яки) аның вәкиле катнашында, видеоязма белән башкарыла.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча карау беркетмәсе төзелә.

76. Сораштыру – инспектор тарафыннан контрольдәге заттан яисә аның вәкиленнән һәм мондый мәгълүматка ия булган башка затлардан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү өчен әһәмиятле булган мәгълүмат алу.

77. Мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, тикшерү, сораштыру үткәргәндә, инспектор мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен фотога төшерү, аудио - һәм видеоязма, дәлилләрне теркәүнең башка ысулларын кулланырга хокуклы.

78. Күчмә тикшерү тәмамланганнан соң инспектор күчмә тикшерү акты төзи.

Фотога төшерү, аудио-һәм видеоязма үткәрү турындагы мәгълүмат тикшерү актында теркәлә.

Актны дистанцион аралашу чараларын кулланып, шул исәптән аудио - яки видеоэлемтә аша тикшерү үткәргән очракта, Нигезләмәнең әлеге пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән нигезләмә кулланылмый.

79. Контрольдәге затның теркәлгән (эшчәнлек алып бару) урынында булмавы сәбәпле, яки контрольдәге зат эшчәнлегенең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, яисә контрольдәге затның күчмә тикшерүне үткәрмәү яисә тәмамламауга сәбәп булган башка гамәлләренә (гамәл кылмауларына) бәйле рәвештә күчмә тикшерү үткәрмәгәндә, инспектор, сәбәпләрен күрсәтеп, күчмә тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзи һәм контрольдәге затка, Федераль законның 21 статьясы 4 һәм 5 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә, контроль чаралар үткәрү мөмкин булмау турында хәбәр итә

Бу очракта инспектор күчмә тикшерүнең ахырына кадәр, әлеге вакыт аралыгында, контроль гамәлләр кылырга хокуклы.

80. Контрольдәге зат булган шәхси эшмәкәр, контрольдәге зат булып торучы граждан Контроль органга түбәндәге очракларда контроль чаралар үткәргәндә булмавы турында мәгълүмат бирергә хокуклы:

1) вакытлыча эшкә сәләтсезлек;

2) суд, хокук саклау органнары, хәрби комиссариат чакыруы (хәбәрнамәләр, повесткалар) буенча бару зарурлыгы;

3) Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексы нигезендә контроль чаралар үткәргәндә булу мөмкинлеген бирми торган чикләү чаралары булу;

4) хезмәт командировкасында булу.

Мәгълүмат кергәндә, Контроль орган контроль чаралар үткәрүне шәхси эшмәкәр һәм гражданның әлеге мөрәҗәгатенә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерә.

## 13. Инспекция визиты

81. Инспекция визиты контрольдәге затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яки контроль объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча үткәрелә.

Инспекция визиты контрольдәге затка һәм җитештерү объекты милекчесенә алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

Контрольдәге затлар яки аларның вәкилләре инспекторның биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

Инспекция визитын үткәрү вакыты бер урында яки бер җитештерү объектында (территориядә) бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

82. Инспекция визиты барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

1) карау;

2) сораштыру;

3) язмача аңлатма алу;

4) документлар таләп итү, алар, мәҗбүри таләпләр нигезендә, контрольдәге затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләрнең) яисә контроль объектының урнашкан (эшчәнлек алып барган) урынында булырга тиеш.

Инспекция визитын дистанцион элемтә чараларын кулланып, шул исәптән аудио - яки видеоэлемтә аша үткәрү рөхсәт ителә.

83. Планнан тыш инспекция визиты, аны уздыруның Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә каралган очраклардан тыш, бары тик прокуратура органнары белән килештереп үткәрелергә мөмкин.

84. Әлеге Нигезләмәнең 82 пунктында каралган контроль гамәлләр әлеге Нигезләмәнең 63, 64, 75-77 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 14. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы)

85. Контроль орган мәҗбүри таләпләрнең (куркынычсызлык мониторингы) үтәлешен күзәткәндә Контроль органда булган контроль объектлары турында, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында керә торган мәгълүматларны, шулай ук «Интернет» челтәрендәге мәгълүматлар, башка һәркем танышу өчен мөмкин булган мәгълүматларны, шулай ук фото һәм кино төшерү, видеоязма, хокук бозуларны теркәүнең автоматик режимда эшләүче техник чараларыннан файдаланып алынган мәгълүматларны җыя, анализлый.

86. Әгәр мәҗбүри таләпләрнең (куркынычсызлык мониторингы) үтәлешен күзәтү барышында зыян (зарар) китерү яки закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы янау фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, мәҗбүри таләпләрне бозуга әзерлек турында яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында мәгълүмат ачыкланса, Контроль орган тарафыннан түбәндәге карарлар кабул ителергә мөмкин:

1) Федераль законның 60 статьясы нигезендә планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чарасын уздыру турында карар;

2) кисәтү игълан итү турында карар.

## 15. Күчмә тикшерену

87. Күчмә тикшерену контрольдәге затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә.

88. Күчмә тикшерену оешманың (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерым структур бүлекчәләрнең) урнашкан (эшчәнлек алып барган), гражданның эш урынында, контроль объектының урнашкан урынында үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контрольдәге зат белән аралашу рөхсәт ителми.

Күчмә тикшерену барышында һәркем өчен файдалану мөмкин (чикләнмәгән затлар даирәсенә керү өчен ачык) булган җитештерү объектларын тикшерү уздырылырга мөмкин.

89. Күчмә тикшерену контрольдәге затка хәбәр итмичә үткәрелә.

Бер объектта (бер-берсенә якын урнашкан берничә объектта) күчмә тикшерүне уздыру вакыты, әгәр Федераль законда башкача билгеләнмәгән булса, бер эш көненнән дә артмый.

## 16. Төп контроль күрсәткечләр төре һәм аларның муниципаль контроль өчен максатчан әһәмияте

90.Муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан әһәмияте, индикатив күрсәткечләр әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы белән билгеләнгән.

## 17. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү

91. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү законнарда каралган тәртиптә башкарыла

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә муниципаль
торак контроле турында
Нигезләмәгә 1 нче кушымта

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында
контроль объектларын куркыныч категориясенә кертү критерийлары

1. Контроль объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә кертү куркыныч күрсәткече дәрәҗәсенә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла:

- куркыныч күрсәткече дәрәҗәсе 6 дан артык булганда, контроль объекты югары дәрәҗә куркыныч категориясенә керә;

- куркыныч күрсәткече дәрәҗәсе 4 - 6 булганда – уртача дәрәҗә куркыныч категориясенә керә;

- куркыныч күрсәткече дәрәҗәсе 2 - 3 булганда – уртачадан кимрәк дәрәҗә куркыныч категориясенә керә;

- куркыныч күрсәткече дәрәҗәсе 0 - 1 булганда – түбән дәрәҗә куркыныч категориясенә керә;

2. Куркыныч күрсәткече дәрәҗәсе түбәндәге формула белән исәпләнә:

$К = 2 \times V_1 + V_2 + 2 \times V_3$, монда:

К - куркыныч күрсәткече дәрәҗәсе;

$V_1$ - контроль объектын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү турында карар (алга таба - эшчәнлекне куркыныч категориясенә кертү турында карар) кабул ителгән елга кадәр ике ел эчендә үз көченә кергән, Контроль орган тарафыннан төзелгән беркетмәләр нигезендә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4.1 статьясында каралган административ хокук бозган өчен контрольдәге затка (аның вазыйфаи затларына) административ җәза билгеләү турында карарлар (алга таба-куркынычлылык категориясенә кертү турында карар) саны;

$V_2$ - контроль объектын куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән елга кадәр ике ел эчендә үз көченә кергән, Контрольным орган тарафыннан төзелгән беркетмәләр нигезендә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.21-7.23 статьяларында, 9.16 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә, 19.7 статьясында каралган каралган административ хокук бозган өчен контрольдәге затка (аның вазыйфаи затларына) административ җәза билгеләү турында карарлар (алга таба-куркынычлылык категориясенә кертү турында карар) саны;

$V_3$ - контроль объектын куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән елга кадәр ике ел эчендә үз көченә кергән, Контрольным орган тарафыннан төзелгән беркетмәләр нигезендә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясындагы 1 өлешендә каралган каралган административ хокук бозган өчен контрольдәге затка (аның вазыйфаи затларына)

административ җәза билгеләү турында карарлар (алга таба-куркынычлылык категориясенә кертү турында карар) саны.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә муниципаль

торак контроле турында
Нигезләмәгә 2 нче кушымта

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Контроль органга контрольдәге затның эшчәнлегендә түбәндәге мәҗбүри таләпләрдән бер генә булса да тайпылу турында граждан яисә күпфатирлы йортта торак милекчеләре булган оешмалар, күпфатирлы йорттагы тораклардан файдаланучы гражданнардан мөрәҗәгать, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат керү:

а) күпфатирлы йортта торакны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торакка күчерү тәртибенә карата;

б) күпфатирлы йортта торакны яңадан планлаштыру һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибенә карата;

в) күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм торактан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә карата;

г) күпфатирлы йортларда инвалидлар өчен торактан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә карата;

д) күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затларның авария-диспетчерлык хезмәтен гамәлгә ашыру өлешендә эшчәнлегенә карата;

е) йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларын кулланганда һәм карап тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итүгә карата.

Әлеге индикаторның булуы закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүнең турыдан-туры янавын күрсәтә һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә планнан тыш контроль (күзәтчелек) чараларын уздыру өчен нигез булып тора.

2. Контроль органга күпфатирлы йортта торак милекчеләре булган граждан яисә оешманың күпфатирлы йорттагы торактан файдаланучы граждан мөрәҗәгате, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында, әлеге типик индикаторларның 1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдән һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә планнан тыш контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрдән тыш, мәгълүмат керү, әлеге мөрәҗәгать кергәнче бер ел дәвамында Контроль орган контрольдәге затка шундый ук мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр игълан иткән булса.

3. Алдагы шундый ук чоры белән чагыштырганда (ай, алты ай, унике ай) һәм

(яки) алдагы календарь елының шул ук чоры белән чагыштырганда, контроль орган адресына күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре булган гражданнардан яки оешмалардан, күпфатирлы йорттагы биналардан файдаланучылар булган гражданнардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында ике тапкыр һәм аннан күбрәк мөрәҗәгатьләр саны (ай, алты ай, унике ай) арткан.

4. Өч ай дәвамында күпфатирлы йортта торак милекчеләре булган граждан яки оешмадан, күпфатирлы йорттагы торактан файдаланучы гражданнан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан һәм торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасында контрольдәге зат тарафыннан урнаштырылган мәгълүматларның (белешмәләрнең) өч ай дәвамында туры килмәвенең биштән артык фактын ачыклау.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә муниципаль
торак контроле турында
Нигезләмәгә 3 нче кушымта

## Муниципаль торак контроленең нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләре исемлеге

| Күрсәткеч номеры | Күрсәткеч атамасы | Исәпләү формуласы | Комментарий (мәгънә интерпретациясе) | Күрсәткечнең база әһәмияте | Күрсәткечне халыкара чагыштыру | Күрсәткечләрнең максатчан әһәмияте | | | Күрсәткечләр максатчан әһәмиятен билгеләү чыганаклары | Күрсәткече булган (булганда) стратегик планлаштыру документлары турында белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | узган ел | агымдагы ел | киләсе ел | | |
| | **ТӨП КҮРСӘТКЕЧЛӘР** | | | | | | | | | |
| **1** | **Законда саклана торган кыйммәтләргә зыянны (зарарны) минимальләштерү дәрәҗәсен чагылдыра торган күрсәткечләр, зыян (зарар) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсе** | | | | | | | | | |
| 1.1. | Күпфатирлы йортларда һәм торак йортлардагы торак милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә гражданнарга, оешмаларга һәм дәүләткә китерелгән матди зыян, тулаем региональ продукттан процентларда | Сп*100/ ВРП | Сп - күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы торактан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә гражданнарга, оешмаларга һәм дәүләткә законсыз хисапланган түләүне яңадан исәпләү суммалары, млн. сум; ҖРП-расланган тулай төбәк продукты, млн. сум; исәпкә алу өчен күрсәткечнең кимендә йөздән бер өлеше (нольдән соң ике билге) төгәллеге белән кабул ителә, күрсәткечләр йөздән бер өлешеннән ким | | | | | | Контроль органының статистик мәгълүматлары: күрсәтмәләр журналы, тикшерүләр реестры статистик мәгълүматлар (Волгоградстат) | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | булганда нольгә тиңләштерелә. | | | | | | | |
| 1.2. | Гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүгә сәбәп булган мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының ачыкланган гомуми саныннан өлеше | КСВ*100% / Ксн | Кспв-гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүгә сәбәп булган, суд карарлары белән расланган мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары саны;<br><br>К сн - тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары; «Правосудие» РФ ДАС мәгълүматлары. | |
| | **ИНДИКАТИВ КҮРСӘТКЕЧЛӘР** | | | | | | | | | |
| **2** | **Контроль эшчәнлеге мониторингы, аны анализлау, аны тормышка ашырганда барлыкка килгән проблемаларны ачыклау һәм зыян (зарар) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсе белән хезмәт, матди һәм финанс ресурслары күләме арасындагы чагыштыруны характерлый торган сәбәпләрне билгеләү өчен кулланыла торган күрсәткечләр, шулай ук контрольдәге затлар эшчәнлегенә тыкшыну дәрәҗәсе** | | | | | | | | | |
| | **2.1. Контрольлек итүче зат белән үзара хезмәттәшлек иткәндә контроль чаралар** | | | | | | | | | |
| 2.1.1. | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелгән тикшерү чараларының гомуми санына карата билгеләнгән срокларда үткәрелгән муниципаль торак контроле кысаларында контроль чараларның өлеше | Пву*100% / Пок | Пву-билгеләнгән срокларда үткәрелгән муниципаль торак контроле кысаларында контроль чаралар саны<br><br>Пок –муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән контроль чараларының гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |
| 2.1.2. | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру барышында муниципаль торак контроле органы биргән күрсәтмәләрнең гомуми санына карата суд тәртибендә законсыз дип танылган күрсәтмәләрнең өлеше | ПРн*100% / ПРо | ПРн- суд белән законсыз дип табылган күрсәтмәләр саны;<br><br>Про- муниципаль торак контроле барышында бирелгән күрсәтмәләрнең гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1.3. | Муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән контроль чараларнның дөрес түгел дип танылган өлеше | Ппн*100% / ПК | Ппн-нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган контроль чараларның саны;<br>Пок - муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән контроль чараларының гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |
| 2.1.4. | Үткәрелгән тикшерү чараларының гомуми саныннан Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып үткәрелгән контроль чараларында, мондый контроль чараларын гамәлгә ашырган муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларына карата дисциплинар, административ җәза чараларыкүрелгән муниципаль торак контроле органы тарафыннан үткәрелгән контроль чаралары, өлеше | Псн*100% /Пок | Псн – аларны үткәрү тәртибе турында РФ законнары таләпләрен бозып муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән аларның нәтиҗәләре буенча, мондый контроль чараларын гамәлгә ашырган муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларына карата дисциплинар, административ җәза чаралары кулланылганконтроль чараларның саны<br><br>Пок-- муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән тикшерү чараларының гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |
| | **2.2. Контрольдәге зат белән үзара бәйләнешсез тикшерү буенча чаралар** | | | | | | | | | |
| 2.2.1. | Контроль чараларның гомуми саны | инспекциянең статистик мәгълүматлары | Муниципаль торак контроле органнарының статистик мәгълүматлары | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2.2. | Муниципаль торак контроле органы<br>тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча суд тәртибендә законсыз дип табылган күрсәтмәләрнең гомуми санына карата өлеше | ПРМБВн*100% / ПРМБВо | ПРМБВн-тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча суд тәртибендә законсыз дип танылган муниципаль торак контроле органы тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрнең саны<br><br>ПРМБВо -контроль чаралары нәтиҗәләре буенча бирелгән күрсәтмәләрнең саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |